| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан<br>Карашай-Сакловское<br>сельское поселение<br>Сармановского<br>муниципального района** | **Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районынын Карашай-<br>Саклау<br>авыл жирлеге** |

---

| | |
|---|---|
| **КАРАР<br>07.08.2025 ел** | **КАРАР<br>№ 12** |

Карашай-Саклау җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге башкарма комитетының салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2025 елның 1 апрель 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 31 маендагы 828 номерлы карарының 2 пунктындагы м пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге башкарма комитетының 2025 елның 01 апрелендэге 7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

17 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Оешмалар табышына салым һәм оешмалар мөлкәтенә салым ташламалары белән бәйле Россия Федерациясе субъектының стимуллаштыручы салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү максатларында әлеге карарның 16 һәм 18 пунктлары нигезендә күрсәтелгән салым чыгымнарының гомуми бюджет эффектына (үз-үзен аклауга) бәя бирергә тәкъдим ителә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе В.В.Хосниева